**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**КАРАР**

2020 елның «23» декабреннән № 348

«Авыл җирендә яшәүче һәм эшләүче гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында»

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында авыл җирендә яшәүче һәм белем бирү учреждениеләрендә эшләүче гражданнарның аерым категорияләренә социаль ярдәм чаралары күрсәтү максатларында һәм «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 23 ноябрендәге 1053 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып, **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында авыл торак пунктларында, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) яшәүче һәм мәгариф оешмаларының, муниципаль белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә, әлеге белем бирү оешмалары җитәкчеләренә һәм аларның урынбасарларына, әлеге белем бирү оешмаларының структур бүлекчәләре җитәкчеләренә һәм аларның урынбасарларына торак урыннары, җылылык һәм ут өчен түләү чыгымнарының 100 проценты күләмендә, торак мәйданының Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән социаль нормасы чикләрен чикләмичә, коммуналь хезмәтләрдән файдалану нормативларын исәпкә алып компенсация бирелә дип билгеләргә. Күрсәтелгән социаль ярдәм чарасы шулай

ук пенсиягә чыккан, 60 һәм 55 яшькә җиткән гражданнарга (ир-атлар һәм хатын-кызлар), шулай ук 2018 елның 31 декабренә «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнарда каралган пенсия билгеләү шартларына туры килгән, әмма 60 һәм 55 яшькә җитмәгән ( ир-атлар һәм хатын-кызларга) , авыл җирендә яшәүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмаларында һәм авыл җирлегендә урнашкан муниципаль белем бирү оешмаларында кимендә 10 ел эшләгән гражданнарга бирелә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмати - телекоммуникацион челтәрендәге "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда htt:/pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитеты
җитәкчесе Р.Р. Фәсахов